# Наше Время!

# Безнең Вакыт!

МАОУ СОШ №4

ФЕВРАЛЬ









## Әти-әни балага якыная

**Мәдәният елыннан Әдәбият елына күчкәндә, яңа проект старт алды. Аның нигезендә 12 ноябрьдә республиканың беренче сыйныф укучылары китапханәләргә килделәр. Ә бу, аз да түгел, күп тә түгел, 42 мең 238 нәни китап сөюче теркәләчәк дигән сүз.**

## 2015 год Год татарских богословов

## 2015 ел Татарстанда Парклар һәм скверлар елы дип игълан ителде

## Безнең кунаклар



## Истәлекле даталар

***11 февраль*** **Татарстан Республикасының Композиторлар берлеге оештырылуга 75 ел (1939)**

***13 февраль*** **Язучы Рәфыйк Кәләметдин улы Шәрәфиевкә 75 яшь (1939)**

***14 февраль*** **Язучы, публицистНияз Рәшит улы Акмал (Акмалов) ның тууына 60 ел (1954–2007)**

***16 февраль*** **Журналист, язучы Фәнзаман Сәетбаттал улы Батталга (Сәетбатталовка) 75 яшь (1939)**

***27 февраль*** **Классик язучы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Шәриф Камалетдин улы Камал (Байгилдиев)ның тууына 130 ел (1884–1942)**



## К 70 летию Победы!

## Бөек Җиңү кайтавазы!

**Главный редактор—Власова М.Д. корреспонденты газеты:Салихова Л., Гарипов А.**

# 2015 ел – Татар дин белгечләре елы
# ДУМ РТ - 2015-й год
# Год татарских богословов

**Риза Фахретдин (1859-1936) был выдающимся мыслителем татарского народа, просветителем, историком, писателем.**

**Садри Максуди (Арсал) (1879-1957) прожил яркую, многогранную и плодотворную жизнь. Он был известным ученым, мыслителем, общественным деятелем и политиком.**

**Хусаин Фаизханов (1823-1866) выдающийся татарский общественный деятель, педагог, историк, востоковед, археограф, каллиграф. Сыграл значительную роль в развитии духовной культуры татарского общества второй половины XIX века.**

**Юсуф Акчура (1876 - 1935) татарский общественно-политический деятель, ученый, чей вклад в формирование татарской и турецкой наций был огромен. Занимался он также и вопросами богословскими.**

**Джамал Валиди (1887-1932) один из ярких и прогрессивных представителей татарского просветительского движения начала XX в., видный историк татарской общественной мысли, основатель татарской профессиональной литературной критики и эстетической мысли. Именно его перу принадлежат первые аналитические литературно-критические труды о произведениях Г.Тукая, Г.Ибрагимова, Ш.Камала, Г.Исхаки. Им были собраны и впервые подготовлены к печати пословицы и поговорки татарского народа и толковый словарь татарского языка.**

**Хади Атласи (1876-1938) Общественный деятель, историк и педагог Хади Атласи является ярким представителем этой когорты татарской национальной интеллигенции дореволюционного периода.**

**Батырша (Абдулла Галиев) (1710/1715 - 1762) Своей деятельностью Батырша снискал авторитет и популярность в народе. К нему обращались с просьбой разрешить вопросы, связанные с наследованием имущества, или разъяснить вопросы, касающиеся шариата.**

**Гаяз Исхаки (1878-1954) выдающийся деятель татарского национального движения, писатель, публицист, издатель и политик.**

**Дэрдеменд (Закир Рамиев) Будущий золотопромышленник, издатель, меценат и поэт Мухамметзакир (Закир).**

**Шигабутдин Марджани известный татарский богослов, шейх Ордена Накшбандия, историк и религиозный реформатор. Вообще Марджани, самая масштабная фигура в истории татар 19 века. Он был не только богословом, он был педагогом, этнографом, археологом, во многом именно благодаря ему началось формирование татар как народа современного типа.**

**Галимджан Баруди (1857-1921) Просветитель через страницы своего журнала пытался показать близость религии и науки.**






## "Мәдәни жомга" яңа баш мөхәррир

## Вахит Шаихович ИМАМОВ (Вахит Шәих улы ИМАМОВ)

**прозаик, публицист, литературовед**

**Родился 18 марта 1954 года в селе Иске Байсар (Старое Байсарово) Актанышского района ТАССР. Член Союза писателей Татарстана. В Набережные Челны приехал в 1982 году. Работал преподавателем в школе, диспетчером на Прессово-рамном заводе, главным редактором издательства «КамАЗ», с 1997 года – ответственный секретарь Набережночелнинской писательской организации, с 2014—председатель Набережночелнинской писательской организациис 2006 года – главный редактор журнала «Майдан». Автор книг «Ир каната» («Крылья», 1988), «Нэзер» («Завет», 1991), «Запрятанная история татар» (1994), «Сэет-батыр» («Саит-батыр», 1994), «Казанская крепость» (Ижевск, 2005) и других.**
**Награждён медалью «В память 1000-летия Казани», является лауреатом литературных премий имени Гаяза Исхаки и имени Эдуарда Касимова, лауреат Государственной премии им. Г. Тукая. Удостоен звания «Заслуженный работник культуры Татарстана».**

МАОУ "СОШ №4"

# Мансур Габдуллович САФИН
# (Мансур Булгари)
# Мансур Габдулла улы САФИН
## поэт, прозаик, переводчик, литературовед.

**Родился 11 мая 1949 года в городе Анжеро-Судженск Кемеровской области. Член Союза писателей Татарстана и Союза Российских писателей. В Набережные Челны приехал в 1978 году из Сергиева Посада. Работал на заводах КамАЗа (1978-1995), в журнале «Аргамак» (1995-1999), педагогическом институте (2000-2001), газете «Бизнес-класс» (2001-2002), журнале «Казань» (2003-2004), с 2004 – профессиональный писатель. Автор книг «Надежда, Вера и Любовь» (1994), «Хәирле иртә» («Доброе утро», 1994), «Край былинный, Мамадышский» (1994), «Сербакчага сәяхәт» (1997, 2000), «Сыерчык бураны» («Скворцовые метели», 2004), «Челныведение» (2006), «Ода Мамадышу» (2007) и других.**

**Награждён семью медалями, почётными знаками «Ударник строительства КамАЗа», «За службу России», «Отличник Гражданской обороны СССР». Является лауреатом премий имени Эдуарда Касимова (1989, 1991), Егора Уткина (1993), Маннура Шайхи (2000).**





**Мансур Сафин татар һәм рус телләрендә яза, тәрҗемә өлкәсендә актив эшли. Ул – ике дистәдән артык шигырь һәм проза җыентыклары, тәрҗемә китаплары авторы. Алар арасында «Мамадыш таңнары» (1992), «Хәерле иртә» (1994), «Надежда, Вера и Любовь» (1994, рус телендә) исемле лирик шигырь тупланмалары, «Кәнфиттән дә тәмлерәк» (1996), «Сербакчага сәяхәт» (1997), «Сыерчык бураны» (2004) исемле балалар китаплары, тәрҗемә бабында рус шигъриятеннән М.Цветаева һәм Н.Рубцов җыентыклары бар. Татар әдипләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү юнәлешендә ул аеруча нәтиҗәле эшли. Көндәлек матбугат битләрендә, үз вакытында бигрәк тә «Аргамак» журналы сәхифәләрендә (русча өлешендә) аның тәрҗемәсендә Кол Шәриф, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Габделҗәббар Кандалый, Зыя Ярмәки, Нур Баян, Гамил Афзал, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов, Габдулла Шәрәфи, Гакыйль Сәгыйрев һ.б. каләм ияләре иҗатыннан күп кенә тезмә һәм чәчмә әсәрләр, ә Эдуард Касыймов, Мәгъсүм Насыйбуллин, Заһирә Гомәрева, Рәшит Бәшәр, Галимҗан Гыйльмановларның аерым китаплары басылып чыга.**

**М.Сафин газета-журналларда, күмәк җыентыкларда, махсус басмаларда дөнья күргән төбәк тарихына, археологиягә, әдәби процесска кагылышлы язмалары, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре, очерклары белән дә укучыларга яхшы таныш. Ул берничә тапкыр «Ел китабы» бәйгеләрендә призлы урыннар яулый, балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен Ш.Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек була.**

**М.Сафин – 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.**



**Мансур Габдулла улы Сафин — татар язучысы, Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур исемендәге премиясе иясе, Эдуард Касыймов, Егор Уткин премияләре лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1997 елдан). Ул 1949 елның 11 маенда Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск шәһәрендә туа. Казан дәүләт университетында укый. Татар һәм рус телләрендә дистәдән артык китап авторы.**

**Рубис Тажи улы Зарипов** 1939 елның 20 апрелендә Татарстан Республикасының (элеккеге Ворошилов) хәзерге Тукай районы Теләнче Тамак авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлый. Мәктәп елларыннан ук шигырьләр белән мавыга. Армиядә, офицер (отставкадагы подполковник) булып хезмәт иткән елларында да шигырьләр яза. Дистәдән артык китап авторы. Дистәләгән шигырьләргә көйләр язган. 1989 елдан Чаллы шәһәрендә яши.

**Өзелмәсен өметләр...**
**Хәзер җәйләр хатын-кызлар өчен**
**Күргәзмә залына әйләнде.**
**Аларның тормышы күлмәк кими,**
**Шәрә тән йөрүгә көйләнде....**
**Әй, замана, кая атлыйсың син,**
**Кая илтәсең җәмгыятьне,**
**Кая карасаң да тәртипсезлек,**
**Тәмам бозыклык басты илне!**







Бу – “шигырьләрем”не күрсәтү өчен түгел, ә укучыларым тормыштагы реаль фактларны ничек бар , шулай кабул итсен өчен эшләнгән эшләр”.

Рубис Зарипов көе, жырлый Айдар Сафаргалин

Әлеге шигъри юлларны кем язды икән дигән уй килдеме башыгызга, җәмәгать? Бу Яр Чаллы шәһәрендә иҗат итүче отставкадагы подполковник Рубис Зарипов сүзләре. Аның дистәгә якын шигырь җыентыгы һәм узе көй язган 4 җырлар китабы бар. Мәктәбебезгә шагыйрь-композитор Рубис ага килеп үзе турында, үзе иҗат иткән шигырьләр һәм җырлар турында бик тә эчтәлекле итеп сөйләде. Балалар өчен дә, укытучылар өчен дә иң күңеллесе аның тальян гармунында уйнап, матур һәм дәртле тавышы белән моңлы татар көйләрен җырлавы булгандыр. Чип-чиста тавыш белән ул сәхнәләрне яңгыратып, үзе язган җырларын да безгә бүләк итте.

НАШЕ ВРЕМЯ! БЕЗНЕҢ ВАКЫТ!

# РУБИС ЗАРИПОВНЫҢ БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

1. Зарипов, Р. Куңелем моңнары [җырлар] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
2. Зарипов, Р. Йөрәгемнән чыккан моңнар: [җырлар] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
3. Зарипов, Р.Т, Гыйбрәтле хезмәт язмалары: [мемуар истәлекләр] / 1961- 1986 елларда хезмәт-төзәту колонияләрендә хезмәт иткәндә тоткыннарны тәрбияләү.
4. Зарипов, Р. Әби, бабамны яратам: [балалар өчен шигырьләр] / Р. Зарипов
5. Зарипов, Р. Т. Хәтер сандыгымнан: [сугыш һәм сугыштан соңгы авыр еллардагы балаларның көн куреше.
6. Зарипов, Р. Бәхәсле бизмән: [повесть, хикәяләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
7. Зарипов, Р. Т. Җырлап яшик әле: [зурлар өчен җырлар] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
8. Зарипов, Р. Балачагым җырлары: [балалар өчен шигырьләр] / Р. Зарипов.
9. Зарипов, Р. Өметләр өзелмәсен: [шигырьләр] / Р. Зарипов. – Яр Чаллы.
10. Зарипов, Р, Чытырманлы юллар: [зурлар өчен шигырьләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
11. Зарипов, Р. Кояш белән дуслаштым: [балалар өчен шигырьләр] / Р. Зарипов.
12. Зарипов, Р. Тормыш диңгезе: [шигырьләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
13. Арсланов, Ф., Зарипов, Р. Теләнче Тамак авылы мәчетләре язмышы.
14. Зарипов, Р. Гомер көзем: [повесть, хикәяләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
15. Зарипов, Р. Минем сахнә гомерем: [тарихи документаль хикәя] / Р. Зарипов.
16. Зарипов, Р. Узганнарга кайтып: [тарихи повесть] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
17. Зарипов, Р. Бары синдә яшәрмен: [балалар өчен шигырьләр] / Р. Зарипов.
18. Зарипов, Р. Җырлап юанам: [җырлар] / Р. Зарипов. – Яр Чаллы.
19. Зарипов, Р. Куңел оча: [җырлар] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе.
20. Зарипов, Р. Тугрылык: [повестьлар, хикәяләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
21. Зарипов, Р. Чишмәлар: [шигырьләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
22. Зарипов, Р. Шпулек [повесть] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе.
23. Зарипов, Р.Т. Сайрар кошлар моңы: [шигырьләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
24. Зарипов, Р. Йөрәк җылысы: [шигырьләр] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
25. Зарипов, Р. Ясир коллыгы: [повесть] / Р. Зарипов.- Яр Чаллы.
26. Зарипов, Р. Зур буласым килә: [балалар шигырьләре] Алабуга
27. Зарипов, Р Мәгарифнең акты йолдызы: [тарихи мемуар] Алабуга
28. Зарипов Р., Фазуллина Л. – Бишегем Теләнче Тамак: [тарихи әсәр] Казан.
29. Зарипов, Р. "Тулпар" школа мужественных и смелых – Яр Чаллы- Җиләк

Зарипов, Р. Хыянят (пьеса)- Алабуга "Андерсен" типографиясы 2013-64 б.



# АУДИОКАССЕТАЛАР

1. Көзге сагыш: [аудиокассета] / А.Таһирова суз., автор Рубис Зарипов.
2. Дүрт шәхескә бер бәхет: [аудиокассета] / Энже Гәйфетдинова, Әнвәр Шарипов суз., Рубис Зарипов көе, җырлый Илсөяр Зарипова. – Яр Чаллы: 2008
3. Яраталмыйм синнән бүтәнне: [аудиокассета] / Энже Гәйфетдинова суз., Рубис Зарипов көе, җырлый Илсөяр Зарипова. – Яр Чаллы: 2009
4. Ярамый, Сөю җыры, Кабатланмас кебек уткәннәр, Кәрәкәс: [җырлар] // Җырларым юлдаш булсын: Рубис Зарипов көе, җырлый Сәрия Нәбиуллина.
5. Эй, кайтасы иде яшьлеккә: / Кадрия Наил суз., автор Рубис Зарипов. Җырларым сезнең өчен: [аудиодиск] / Рубис Зарипов җырлары.
6. **Халкым өчен җырлыйм: / Халык җырлары Рубис Зарипов башкаруында.**





**Айдар Хәлим 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә.**

**Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигъриятtә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган.**






# Шафигуллин Рахман Галимович

**Экс-директор редакции телерадиовещания (Челны-ТВ") Республики Татарстан;заслуженный деятель культуры, писатель, журналист родился 2 июня 1949 года в деревне Верхний Тимерлик Рыбно-Слободского района ТАССР; в 1977 году окончил отделение печати, радио и телевидения Высшей партийной школы (Ленинград); в 1965 - 1969 гг. - столяр-станочник в г. Воркута (Коми АССР); после службы в рядах Советской Армии стал литературным сотрудником районной газеты "Октябрь Юлы" (п. Рыбная Слобода); в 1973 - 1977 гг. - учеба в Высшей партийной школе; в 1977 - 1984 гг. - работал заместителем редактора Тукаевской районной газеты "Якты юл" (г. Набережные Челны); в 1984 - 1992 гг. - собственный корреспондент Гостелерадио ТАССР по Набережночелнинской зоне; в 1992 - 1995 гг. - главный редактор городской редакции телерадиовещания; в 1996 - 2000 гг. главный редактор газеты "Менделеевские новости" (г. Менделеевск); с 2001 года - директор - главный редактор телерадиокомпании "Чаллы-ТВ"; депутат Набережночелнинского (1990 г.) и Менделеевского (1999 г.) городских Советов народных депутатов; Заслуженный работник культуры Республики Татарстан; награжден почетным знаком "Ударник строительства КАМАЗа"; почетной грамотой президента Республики Татарстан за большие заслуги в области СМИ республики. Автор книги повестей и рассказов на татарском языке “Йозак”.**




**Фәүзия Аухади кызы Бәйрәмова – Татар халкының күренекле сәясәтчесе, язучысы, җәмәгать эшлеклесе. Иттифак фиркасе башлыгы, Милли Мәҗлес рәисе. 1990 елларда бик актив сәясәтче, аны хәтта *Татар фәрештәсе* дип атыйлар һәм Сөембикә белән чагыштыралар. Фәүзия Бәйрәмова 1950 елның 5 декабренда ТАССРның Саба районының Сабай авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул белемен башта Казанның театр училищесында, аннары Казан Дәүләт университетының филология факультетында дәвам итә (1983-1989). Профессиональ эшчәнлекне Фәүзия Бәйрәмова Казан телестудиясендә башлый. Соңрак ул китап нәшриятында эшли. Журналист һәм мөхәррир буларак, ул күп газета-журналларда яза.**

**1986 елда ул СССР язучылар берлегенә әгъза итеп алына.**

**1988 елда ул Татар иҗтимагый үзәгенең беренче корылтаенда катнаша, сәяси эшчәнлеккә кереп китә.**

**Хәзерге вакытта Фәүзия ханым Яр Чаллы шәһәрендә яши һәм язу эше белән шөгыльләнә. 1999 елда Хаж кыла.**




**"Сәнгать дөньясына сәяхәт" (1989), "Моң" (1991), "Мәйдан татарларны күтә" (1992), "Кара урман" (1997), Безне онытмагыз" (1998),**

**"Дәверләр күчешендә" (1998). "Хаж көндәлеге" (1999) "Заман. милләт. Кеше. " (2000) "Күңел карлыгачларым" (2000) "Соңгы намаз" (2000) "Мишәрнең бөек улы " (2001) "Алыплар илендә" (2002) "Ахырзаман афәте" (2002) "Бәхет ачкычы" (2002) "М Худяков и история татарского народа" (2003) "Таралып яткан татар иле" (2003) "Нух пәйгамбәр көймәсе" (2004) "Ислам яшәү рәвеше." (2004 "Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше" (2004) "Ядерный архипелаг или атомный геноцид против татар" (2005) "Кырык сырт" (2005) "Алтын Урдам - алтын җирем" (2006) "Баhадиршаh" (2006) "Der Nukleare Archipel oder der atomare Genozid an den Tataren" (2006) " Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Среднего Поволжья" (2007) "Тропою знаний к истине" (2007) "Татарская Караболка - 50 лет в объятиях смерти" (2007) "Күчем хан" (2007) "Туран Иле" (2008) "Милләт һәм дәүләт. (2009) "ГУЛАГ - яралы язмышлар" (2010) "Ачылмаган татар тарихы" (2011) "Күчем хан" (2011) "Батырша явы" (2012) "Нераскрытая история татар" (2013)**

**МАОУ "СОШ №4"**

# Новости Яналыклар






**С 26 по 31 января в нашем классе прошла акция “Неделя без телефонов”. Мы остались довольны. Класс стал общительным, более внимательным. Больше времени стали проводить вместе. Эта акция не последняя. В дальнейшем мы периодически будем проводить подобные мероприятия. Неожиданно для класса, у многих появилось больше интересов, кто-то раскрыл свой удивительный мир. Этой акцией остались довольны не только ученики, но и учителя, а также родители.**

**Ученики 8А.**

**Прошёл 1 этап Всероссийского конкурса чтецов «Живая классика», в котором приняли участие 6-7 классов: Рахманов Рамазан (6В класс), Ризванова Диляра (7А класс), Хамидуллин Булат (6А класс) ,Нигматуллина Азалия (6А класс), Валеева Дана (6А класс).**



**В финал вышли Рахманов Рамазан 6В (рассказ Сергея Алексеева «Папка», учитель Ханбекова С.Н.), Ризванова Диляра 7А( отрывок из рассказа К.Г.Паустовского «Старый повар», учитель Ханбекова С.Н.), Хамидуллин Булат 6А (отрывок из рассказа А.Н.Толстого «Русский характер», учитель Тимерфулатова Ф.М.).**



**«Ватан сакчыларына дан!» - фәнни региональ эш.**

**1нче урын Хазиев Булат 9В. (Укытучы—Батдалова С. А.)**

**Котлыйбыз!**

# Яр Чаллы шәһәренең
# 4 нче мәктәп укучылары яза.



## Кызыклы очрашу.

**Быел Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнәбез. Моның өчен шәһәребездә дә,мәктәбебездә дә бик күп чаралар үткәрелә. Сыйныф сәгатьләре, ветераннарның өйләрендә булу, төрле очрашулар, викториналар үткәрү кебек чаралар уза. Күптән түгел шәһәребезнең балалар китапханәсендә “Җиңүнең 70 еллыгы”на һәм“Ленинград блокадасының 71 еллыгы”на багышланган тематик кичә булды. Кичәне китапханә хезмәткәрләре Фәния Вазитовна һәм Резеда Вагизовна әзерләделәр һәм алып бардылар. Кичә шундый эчтәлекле,хәтта күзләргә яшь килерлек дәрәҗәдә иде. Җырлар,шигырьләр, хатлардан өзек тыңлау бик тәэсирле булды.Бигрәк тә Ленинград блокадасының 125 грамм ипиен күрсәткәч, барыбыз да тетрәнеп киттек. Хәзерге мул тормышта яшәвебез турында барыбыз да уйланып куйдык. Кичә азагында викторина сорауларына җавап бирдек. Китапханәгә безне сыйныф җитәкчебез Азалия Рәсимовна алып барды. Без аларга бик рәхмәтле. Кичәдә алган тәэсирләребез әле озакка җитәр,без үзебезнең рәхәт,тыныч тормышта яшәвебез белән бик бәхетле икән дип уйланып,сөйләшеп кайттык. Иншаллаһ, гел тыныч тормыш бирсен! Илебез сугышлар күрмәсен!**

**Хашитова Ләйлә,8 В сыйныфы укучысы.**

## Әнием намаз укый.

Ак яулыклы,чиста күлмәк кигән
Әнием утыра намаз укырга.
Хәйран калып аны күзәтәм мин,
Сокланудан чыкмый аваз да.
Иң элек ул әрвахларга кыла дога,
Җиребезгә сорый игелек.
Сугышлардан сакла,Ходаем,афәтләрдән,
Бирә күрмә безгә читенлек.
Яңгыр сорый,яңгыр яумый торса,
Игеннәргә сорый мул уңыш.
-Ризыклар,-ди,-бәрәкәтле булсын,
Тыныч була күрсен бу тормыш.
-Шәфкатьлелек иңдер һәр балама,
Сакла аларны җилдән, давылдан.
Юлларына киртә куя күрмә,
Мәрхәмәтсез усал кавемнән.

### Икәү намаз укыйбыз.

**Әнием иртә тора да,
Кулына Коръән ала.
Изге китапны укып ул
Күңелдән дога кыла.
Әниемне бик яратам –
Шигырем аның турында.
“Иманлы бул,балам,” – сүзе
Һәрчак минем уемда.
Намаз укып,дога кылып,
Телим изге теләкләр:
Җәннәттә дә бергә булыйк,
Кабул булсын теләкләр!**

Нәбиуллина Нәбилә, 8 Всыйныфы укучысы.